**Серле урман**

1) Урманга сокланып йөрим,
   Чишмәләр көен тыңлап.
   Әкияткә килеп кердем,
   Тылсымлы сукмак буйлап.

Кушымта:
Күпме сер, могҗиза яши
Шушы урман юлында
Күңелгә нур, илһам тула
Гүзәл урман куйнында.

2) Яфракларга сыенышып
   Кошлар моңлы көй суза.
   Җырны бозмаска дип җилләр
   Аларны урап уза.

3) Яшел келәмдәй аланда,
   Гөлләр күзне иркәли.
   Җиләкләргә шифа биреп,
   Ләйсән яңгыр сибәли.